**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80.
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80.
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы**

**КАРАРЫ**

**2016 елның «28» июненнән** **№ 15-63**

**2016 елга җир өчен аренда түләвен түләүдән азат итү турында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 65 статьясындагы 1 пункты нигезендә, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары, Яңа Чишмә муниципаль районының норматив хокукый актлары нигезендә Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2016 елда җир өчен аренда түләвеннән җирле бюджетка бер җир участогына, түбәндәге физик затларга карата бер арендаторга күчерелә торган сумманың 100 % азат итәргә:

1) Советлар Союзы Геройларын, Россия Федерациясе Геройларын, Дан орденының тулы кавалерларын;

2) I һәм II инвалидлык төркеме булган инвалидларны;

3) балачактан инвалидларны;

4) Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм инвалидларын;

5)«Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы (1992 елның 18 июнендәге 3061-I номерлы Россия Федерациясе Законы редакциясендә), 1998 елның 26 ноябрендәге «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыкларны ташлау нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 175-ФЗ номерлы Федераль закон, 2002 елның 10 гыйнварындагы «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган

гражданнарга социаль гарантияләр турында» 2-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә социаль ярдәм алуга хокукы булган физик затларны;

6) махсус куркыныч бүлекчәләре составында атом-төш һәм термоатом-төш коралы сынауларында һәм хәрби объектларда атом-төш җайланмаларының аварияләрен бетерүдә турыдан-туры катнашкан физик затларны;

7) атом-төш җайланмаларының теләсә нинди төрләре белән бәйле сынаулар, өйрәнүләр һәм башка эшләр, шул исәптән атом-төш коралы һәм космик техниканы да кертеп, сынаулар, өйрәнүләр һәм башка эшләр нәтиҗәсендә инвалид булган физик затларны.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2016 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә (комиссия рәисе Дворецкая С.П.).

**Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**